**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1729**
**20.02.2026**

«Беренчеләр инициативасы» социаль әһәмияткә ия проектлар конкурсын оештыру һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2025 елның 29 октябрендәге 8855 номерлы карары белән расланган «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсенә Яр Чаллы шәһәрендә 2026 елның июнендә «Беренчеләр инициативасы» социаль әһәмияткә ия проектлар конкурсын (алга таба – конкурс) үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурсны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны оештыру һәм үткәрүгә чыгымнарны финанслауны, 2026 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 2 000 000 (ике миллион) сум 00 тиен күләмендә тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 20 февралендәге
1729 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Беренчеләр инициативасы»
социаль әһәмияткә ия проектлар конкурсы турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Беренчеләр инициативасы» социаль әһәмияткә ия проектлар конкурсы (алга таба-конкурс) гомуми белем бирү, һөнәри белем бирү учреждениеләре, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре базасында тематик клубларның командалары, «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең (алга таба – «Беренчеләр хәрәкәте») Беренчел бүлекчәләренең Беренчеләр Советлары арасында үткәрелә.

2. Әлеге нигезләмә 2026 елда конкурс үткәрү шартларын һәм тәртибен билгели.

2 бүлек. Конкурсның максатлары

3. Конкурс балаларның һәм яшьләрнең социаль әһәмияткә ия проектларын (инициативаларын) стимуллаштыру һәм аларга ярдәм күрсәтү, актив гражданлык позициясен формалаштыру һәм Яр Чаллы шәһәрендә «Беренчеләр хәрәкәте» эшчәнлеген үстерү максатларында үткәрелә.

3 бүлек. Конкурста катнашучылар

4. Түбәндәгеләрнең командалары конкурста катнашучылар булырга мөмкин:

1) гомуми белем бирү, һөнәри белем бирү, өстәмә белем бирү, спорт, мәдәният, яшьләр сәясәте учреждениеләре базасында «Беренчеләр хәрәкәте» тематик клублары;

2) гомуми белем бирү, һөнәри белем бирү учреждениеләре базасында «Беренчеләр хәрәкәте» беренчел бүлекчәләренең Беренчеләр советлары;

3) балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре.

5. Команда составында 12 дән 17 яшькә кадәр 5 тән 10 га кадәр кеше булырга мөмкин.

4 бүлек. Конкурс номинацияләре

6. Конкурска «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт балалар һәм яшьләр хәрәкәте эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча чаралар үткәрүне күздә тоткан проектлар тәкъдим ителергә мөмкин.

7. Әлеге нигезләмә белән конкурсның түбәндәге төп номинацияләре билгеләнә:

1) «Укы һәм танып-бел!» (белем алу һәм белемнәр);

2) «Сәләтеңне эзлә!» (хезмәт, һөнәр һәм үз эше);

3) «Иҗат ит һәм илһамландыр!» (мәдәният һәм сәнгать);

4) «Игелек кыл!» (волонтерлык һәм ихтыяри ярдәм);

5) «Ватанга хезмәт ит!» (патриотизм һәм тарихи истәлек);

6) «Иреш һәм җиңү яула!» (спорт);

7) «Иң мөһиме турында сөйлә!» (медиа һәм коммуникацияләр);

8) «Дус була бел!» (дипломатия һәм халыкара мөнәсәбәтләр;
9) «Планетаны сакла!» (экология һәм табигатьне саклау);
10) «Илне ач!» (туризм һәм сәяхәт);
11) «Сәламәт бул!» (сәламәт яшәү рәвеше);
12) «Кыю бул һәм ачыш ясa!» (фән);
13) «Туган як» (милли тел, мәдәният һәм традицияләр).
8. Команда һәр номинациядә конкурска бердән артмаган проект тәкъдим итәргә мөмкин.

## 5 бүлек. Конкурсны оештыручылар

9. Конкурсны оештыручылар булып тора:
1) Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе;
2) «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең Яр Чаллы шәһәрендәге җирле бүлекчәсе.
10. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.
Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:
1) заявкаларны кабул итә;
2) конкурс сынауларын үткәрүне оештыра;
3) конкурска йомгак ясый.
11. Оештыру комитеты әлеге нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган бәяләү критерийлары нигезендә, конкурста катнашу өчен җибәрелгән заявкаларны бәяләүне гамәлгә ашыра;

## 6 бүлек. Конкурста катнашуга заявкаларны җибәрү тәртибе

12. Конкурста катнашу өчен команда конкурсның оештыру комитетына, әлеге нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралганча, рус телендә түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган заявка җибәрә:
1) проект буенча планлаштырылган эшчәнлек күбесенчә туры килә торган конкурс номинациясе;
2) проектның исеме;
3) проектның кыскача тасвирламасы;
4) проектның масштабы;
5) проектны тормышка ашыру срогы;
6) проектның социаль әһәмиятен нигезләү;
7) проектның максатчан төркемнәре;
8) проектның максаты һәм бурычлары;
9) проектның көтелгән сан һәм сыйфат ягыннан нәтиҗәләре;
10) проектның календарь планы;
11) проектның сметасы;
12) проект командасы турында мәгълүмат.
13. Конкурста катнашу шарты булып, команда тарафыннан әлеге нигезләмәгә 3 нче кушымтада каралганча, түбәндәге типларның берсенә: гомуми белем бирү оешмаларына, һөнәри белем бирү оешмаларына, өстәмә белем бирү, спорт, мәдәният, яшьләр сәясәте оешмаларына караган партнер-оешмадан ярдәм күрсәтү хатын тапшыру тора.
14. Гариза һәм ярдәм күрсәтү хаты «Проектлар конкурсы» билгесе белән rddm_nch@mail.ru электрон почта адресына җибәрелә.

## 7 бүлек. Конкурсны үткәрү сроклары

15. Конкурста катнашу өчен заявкалар тапшыру 2026 елның 30 апрелендә

22:00 сәгатькә кадәр гамәлгә ашырыла.

16. Оештыру комитеты тарафыннан заявкаларны бәяләү 2026 елның 19 маена кадәр гамәлгә ашырыла.

17. Конкурс нәтиҗәләрен игълан итү һәм конкурс җиңүчеләрен бүләкләү «Яшьләр көне — 2026» шәһәр бәйрәме кысаларында 2026 елның 27 июнендә башкарыла.

18. Конкурсның җиңүче проектларын тормышка ашыру 2026 елның 1 декабренә кадәр гамәлгә ашырыла.

19. Конкурсның җиңүче проектларын тормышка ашыру турында хисаплар 2026 елның 10 декабренә кадәр, әлеге нигезләмәгә 4 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча rddm_nch@mail.ru электрон адресына җибәрелә.

## 8 бүлек. Конкурска йомгак ясау һәм финанслау

20. Конкурс җиңүчесе оештыру комитеты тарафыннан конкурста катнашучының заявкасына эксперт бәяләмәсе йомгаклары буенча җыелган баллар суммасы буенча билгеләнә.

21. Һәр конкурс номинациясендә бер җиңүче проект билгеләнә.

22. Заявканы бәяләү йомгаклары буенча, оештыру комитеты конкурс номинацияләренең берсендә җиңүче проектны билгеләү мөмкин булмау турында карар кабул иткән очакта, конкурсның калган номинацияләренең берсендә өстәмә җиңүче проектны билгеләргә мөмкин.

23. Бер җиңүче проект өчен призның күләме заявкада күрсәтелгән суммага бәйле рәвештә 50 000 сум 00 тиеннән 100 000 (йөз мең) сум 00 тиенгә кадәр тәшкил итә.

24. Конкурсның гомуми фонды 2 000 000 (ике миллион) сум 00 тиен тәшкил итә.

25. Приз акчаларын файдалану бары тик проектны тормышка ашыру белән бәйле чыгымнарга гына рөхсәт ителә.

26. Тапшырылган приз хисабына түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыру тыела:

1) проект чараларын тормышка ашыруга җәлеп ителгән юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм (яки) физик затлар хезмәтләренә түләү белән бәйле чыгымнар, призга бүленгән сумманың 30 процентыннан артык булмаган күләмдә;

2) проектны тормышка ашыру белән бәйле булмаган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар;

3) күчемсез объект сатып алуга, капиталь ремонт үткәрүгә, биналар һәм корылмалар төзүгә чыгымнар;

4) халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтүгә чыгымнар;

5) проект турында түләүле басма материал урнаштыруга бәйле чыгымнар.

27. Приз акчаларын түләү, оештыру комитеты беркетмәсендә шарт итеп куелган сумманы җиңүче проект оешмасының исәп-хисап счетына күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

28. Конкурсны финанслау Яр Чаллы шәһәренең муниципаль бюджет акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

«Беренчеләр инициативасы»
социаль әһәмияткә ия
проектлар конкурсы турында
нигезләмәгә
1 нче кушымта

«Беренчеләр инициативасы»
социаль әһәмияткә ия проектлар конкурсында катнашуга
заявкаларны бәяләү критерийлары

| № т/б | Бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| 1 | Проектның актуальлеге һәм социаль әһәмияте | 1 дән 10 га кадәр |
| 2 | Проектның логик бәйләнеше һәм тормышка ашырылуы, проект чараларының аның максатларына, бурычларына һәм көтелгән нәтиҗәләргә туры килүе | 1 дән 10 га кадәр |
| 3 | Проектның инновацион булуы, уникальлеге | 1 дән 10 га кадәр |
| 4 | Проектны тормышка ашыру өчен планлаштырылган чыгымнар һәм аның көтелгән нәтиҗәләре, нәтиҗәләрнең үлчәнеш һәм ирешүчәнлек нисбәте | 1 дән 10 га кадәр |
| 5 | Проект бюджетының реалистик булуы һәм проектны тормышка ашыру өчен планлаштырылган чыгымнарның нигезле булуы | 1 дән 10 га кадәр |
| 6 | Проектны тормышка ашыру масштабы | 1 дән 10 га кадәр |
| 7 | Команданың үз өлеше һәм проектны тормышка ашыруга җәлеп ителә торган өстәмә ресурслар, аның алга таба үсеш перспективалары | 1 дән 10 га кадәр |
| 8 | Оешманың тиешле эшчәнлек юнәлеше буенча программаларны, проектларны уңышлы тормышка ашыру буенча тәҗрибәсе | 1 дән 10 га кадәр |
| 9 | Проект командасының тәҗрибәсе һәм компетенцияләре планлаштырылган эшчәнлеккә туры килүе | 1 дән 10 га кадәр |
| 10 | Оешманың мәгълүмати ачыклыгы | 1 дән 10 га кадәр |

«Беренчеләр инициативасы»
социаль әһәмияткә ия
проектлар конкурсы турында
нигезләмәгә
2 нче кушымта

2026 елда «Беренчеләр инициативасы»
социаль әһәмияткә ия проектлар конкурсында катнашуга
заявка

<table>
<tr><th>№ т/б</th><th colspan="2">Заявка бүлекчәсе</th><th colspan="3">Эчтәлек</th></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="2">Проект буенча планлаштырылган эшчәнлек күбесенчә туры килә торган конкурс номинациясе</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td>2</td><td colspan="2">Проектның исеме</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td>3</td><td colspan="2">Проектның кыскача тасвирламасы</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td>4</td><td colspan="2">Проектның масштабы (катнашучылар саны)</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td>5</td><td colspan="2">Проектны тормышка ашыру срогы</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td>6</td><td colspan="2">Проектның проблематикасын һәм социаль әһәмиятен нигезләү</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td>7</td><td colspan="2">Проектның максатчан төркемнәре</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td>8</td><td colspan="2">Проектның максаты һәм бурычлары</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td>9</td><td colspan="2">Проектның көтелгән сан һәм сыйфат ягыннан нәтиҗәләре</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td rowspan="3">10</td><td colspan="5">Проектның календарь планы</td></tr>
<tr><td colspan="2" rowspan="2">Чара</td><td>Кыскача тасвирлама</td><td>Үткәрү сроклары</td><td>Үткәрү урыны</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td rowspan="4">11</td><td colspan="5">Проект сметасы</td></tr>
<tr><td>Чыгымнар исеме</td><td>Саны (данә)</td><td>Бәясе (сум)</td><td>Барысы (сум)</td><td>Нигезләү</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td rowspan="4">12</td><td colspan="5">Проект командасы турында мәгълүмат:</td></tr>
<tr><td colspan="2">Гариза бирүче команданың исеме.</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td colspan="2">Партнер оешманың исеме.</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td colspan="2">Команданың персональ составы, элемтә мәгълүматлары, шәхси казанышлары</td><td colspan="3"></td></tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| 14 | 13. Проектларны тормышка ашыру тәҗрибәсе | |
| | Өстәмә мәгълүмат:<br>1. Социаль челтәрләрдә команда берләшмәләренә сылтама;<br>2. Чит оешмаларның тәкъдимнәре (теләк буенча) | |

«Беренчеләр инициативасы»
социаль әһәмияткә ия
проектлар конкурсы турында
нигезләмәгә
3 нче кушымта

ОЕШМАНЫҢ ФИРМА БЛАНКЫНДА

«Беренчеләр инициативасы»
социаль әһәмияткә ия проектлар
конкурсының оештыру комитетына

(команданың партнер оешмасының исеме) моның белән проектны (проектның исеме) тормышка ашыруда (команданың исеме) оештыру ярдәме күрсәтергә әзерлеген раслый.

Проектка ярдәм күрсәтү кысаларында (команданың партнер оешмасының исеме), грант акчалары исәп-хисап счетларына күчерелгәннән соң, проект бюджеты нигезендә һәм (команда исеме) заявкасы буенча, проектны (проект исеме) тормышка ашыру чыгымнарын түләүне тәэмин итәргә бурычлы.

Оешма җитәкчесе ____________________ Ф.И.А.и.
(имза)

М.У.